Фәйзрахманов, Ә. Хушлашмыйча китеп барды: [Шагыйрь Фәннүр Сафин турында] / Р. Шәрәфиев // Татарстан яшьләре. – 2023. – №37 (21 сентябрь). – Б. 12.

# Хушлашмыйча китеп барды



**Фәннур Сафин яшьли китеп барган талантлы шагыйрьләребезнең берсе. Быел аның тууына 75 ел тулды. Кызганыч, ул безнен арадан бик иртә, нибары 44 яшендә китте.**

Фәннурның студент чорында да, ул төрле матбугат чараларында эшләгәндә дә миңа анын белән аралашып яшәргә, аның язмалары, шигырьләре белән танышып барырга туры килде. Чыннан да, бик актив, сәлетле егет иде ул.

Фәннур Шәйхенур улы Сафин 1948 елның 27 июненде Минзәлә районының Күзкәй авылында (хәзер бу авыл Тукай районы составына керә). Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң Фәннур бөтен гомерен иҗатка багышлый. Башта радиода, аннары "Татарстан яшьләре" газетасында, "Ялкын" һәм "Казан утлары" журналларында, 'Мәгариф" нәшриятында әдәби хезмәткәр булып эшли.

1983-1987 елларда Фәннур Сафин - Татарстан язучылар берлегендә әдәбиятны пропагандалау булеге хезмәткере. Аның тәүге шигырьләре "Беренче карлыгачлар" (1970) һәм "Юл башы" (1972) коллектив жыентыкларда басылып чыга. 1976 елда автор "Кеше юлга чыкса", 1980 елда "Сез кемнәр?", 1982 елда "Тынлык", 1985 елда "Кукчәчәк",1988 елда "Чәчәк гомере" шигырь жыентыкларын укучыларына тәкъдим итә.

Татар халкының язмышы турында лирик уйланулар, жамгыятьтә буынар алмашы автор поэзиясенең төп тематикасын тәшкил итә. Ф.Сафин шигырьләренә байтак жырлар язылган. Күбрәк ул Р.Гатауллин (Хушлашырга ашыкма"), Б.Мулюков ("Ж,ырымда юатырмын") Ф.Хатыйпов ("Моңлану") кебек композиторлар белән уртак тел табып иҗат итә. Ул җырлар бүген дә бик популяр.

Ф.Сафин нигездә лирик шагыйрь. Аньң шигырьләре яшьлек романтикасы белән сугарылган. Аларга халыкчанлык, бераз моңаю, шул ук вакытта нечкә юмор да хас. Мондый үзенчелекләр "Сез кемнәр?", "Тыңлык", "Кукчәчәк" ж,ыентыкларына кертелгән шигырьләренде аеруча нык сизелә.

Фәннур үзе исән вакытта ук бик талантлы шагыйрьләр исәбенә кертелгән. Рафаэль Мостафин шундый бер факт китерә.

Поляк әдәбиятчысы һәм тәржемече Юрий Велюнский поляк һәм инглиз телләрендә чыгарылган дөнья поэзиясе җыентыгын әзерләгәндә китапка татарлардан Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил белән янәшә Фәннурны да кертә. Әлбәттә, Фәннур Шәйхинур улы гажәеп талантлы, чын мәгънәсендә милли шагыйрь булган. Шуңа күрә аны Сибгать Хәким, Илдар Юзиев, Шәүкет Галиев кебек аксакал әдипләр бик иртә күреп алалар. Мондый сирәк очрый торган талантның нигезенда нәрсә ята соң? Әлбәттә, беренче чиратта туган ягына, халкына мәхәббәт. Әйтик, шигырьләрендә ул җил образын киң файдаланган. Гадеттә бу күренеш тыныч җилден башлана, көчле давыллары белән тәмамлана. Җил татар поэзиясендә аерылышу, борчу, күңелсез хәбәрлер таратучы, сәяхәт итүче рух символы булып исәпләнә. Фәннурнең үзе исән вакытта ук дөнья күргән "Кукчәчәк" китабыннан мисал китереп узыйк. "Имән төбендә уйланулар" шигырендә автор җилне борчу уятучы, кешене нык борчучы күренеш буларак сурәтли. Шигырь ахырында исә җил кешегә бәхет китерүче буларак тасвирлана.

Автор бураннарның да һәрвакыт җанга зыян гына салмавын билгели. Алар туктаусыз зарарлы гына булмый икән. Көчле җилләр, бураннар барлык табигать күренешләре кебек күңелне дә күтәрәләр. Күк йөзе һәм кояш нурлары еш кына җир йөзен иркәли, кешегә шатлык алып килә.

Ни кызганыч, 44 яшендә дөньядан киткән Фәннурнең таланты тиешенчә ачылып җитми калды. Дөресен генә әйткендә аның иҗаты да тиешле бәһасен алмады. Югыйсә радиолардан көн саен диярлек яңгырап торган җырлары гына да ни тора!

Әгъзам Фәйзрахманов